ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Дружба торак пунктында2024 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2023 елның 17 ноябре, № _2_

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

**Карар:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге Дружба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизация, контракт төзеп хэрби операциягә киткән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1)Дружба торак пунктында коеларны ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) Дружба торак пунктында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм лампалар урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

3. Әлеге карарны Ләке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында ( http:// sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы _______ Ю.Г.Антонов